ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.12.2024 № 16

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 21.03.2017 ел, № 4 «Гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итүнең рекреацион зоналарын булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 21.03.2017 ел № 4 карары белән расланган Гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итүнең рекреацион зоналарын булдыру һәм алардан файдалану Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 статьяның 2.2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану Россия Федерациясе Су кодексының 50 статьясы нигезендә раслана торган рекреацион максатларда су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен исәпкә алып, шулай ук шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.»

- 2 статьяның 9-11 абзацларын түбәндәге эчтәлекле 9-12 абзацларга алмаштырырга:

«Рекреацион билгеләнештәге җирләргә рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру (туризм, физик культура һәм спорт, гражданнарның ялын оештыру һәм сәламәтлеген ныгыту өлкәсендә эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү) өчен файдаланыла торган җирләр керә.

Рекреацион билгеләнештәге җирләрдә рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар төзү рөхсәт ителә. Мондый объектлар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар белән килешү буенча урнаштырылган юллардан, сукмаклардан һәм трассалардан файдалану сервитутлар нигезендә гамәлгә ашырылырга мөмкин, бу чакта күрсәтелгән җир кишәрлекләре файдаланудан алынмый.

Рекреацион билгеләнештәге җирләрдә хуҗалык эшчәнлеге мондый җирләрне һәм аларда урнашкан объектларны саклауның һәм алардан файдалануның, шул исәптән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның, рөхсәт ителгән төзелешнең билгеләнгән режимын үтәгәндә рөхсәт ителә».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма**
**комитеты җитәкчесе** **И. К. Свистунов**